РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЛАИШЕВО

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

2024 елның «25» июле 11 номер

# КАРАР

**Кадастр номеры 16:24:170146:34 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерүне, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 24 июлендәге 01-09-13593 номерлы мөрәҗәгате нигезендә, Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма комитеты

**карар чыгарды**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Лаеш шәһәре-«бакчачылык алып бару» адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының кадастр номеры 16:24:170146:34 булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.;

2. Кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру чорын - гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый;

3. Эш комиссиясенә 16:24:170146:34 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карары проектын карау буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр итәргә;

1.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне дәвамында әлеге Карарның 3.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы билгеләгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

1.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

1.4. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән соң ике эш көне дәвамында Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә, карар кабул итү өчен документлар комплекты кушымтасын җибәреп, хәбәр итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев